# Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының "Иске Чекалда авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Иске Чекалда торак пунктында гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында карар

**13.11.2024 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 13 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыеннарының нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы "Иске Чекалда авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Иске Чекалда торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, студентлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче затлардан һәм ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгән, ирекле рәвештә киткәннәрдән) һәм аларның гаилә әгъзаларын (аларның ата-аналарын, хатыннары, балигъ булмаган балаларын) түләүдән азат итеп һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне үтәү буенча алынган мәсьәләләрне хәл итүгә юллап, түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдереп, гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга: 2025 елда үзара салым акчасын 500 сум күләмендә кертү һәм куллану белән килешәсезме?:

1) Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен ремонтлау (лампаларны, дроссельләрне, фонарьларны алыштыру, электрикка хезмәт килешүе буенча түләү һәм урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка чыгымнар).
2) Торак пункт территориясен төзекләндерү (үлән һәм чүп үләннәрен чаптыру, юлларны кардан чистарту, тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, трактор өчен запас частьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алу, тракторчыга хезмәт килешүе буенча түләү һәм территорияне төзекләндерү буенча башка чыгымнар).
3) Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (янгыннарны сүндерү өчен җайлаштырылган техниканы тоту өчен бина төзү материаллары сатып алу һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка чыгымнар).

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 164 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 84 кеше, бу 51,2 % тәшкил итә

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында 84 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының “Иске Чекалда авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Иске Чекалда торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының “Иске Чекалда авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Иске Чекалда торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, студентлардан, укытуның көндезге формасында белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарында булучы затлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (мобилизацияләнгән, иреклеләр контракты буенча хәрби хезмәткәрләр) һәм аларның гаилә әгъзаларын (ата-аналарын, ирләрен хатыннарын, балигъ булган балаларны) түләүдән азат итеп, 2025 елда үзара салым чараларын 500 сум күләмендә кертергә.

3. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен ремонтлау (лампаларны, дроссельләрне, фонарьларны алыштыру, электрикка хезмәт килешүе буенча түләү һәм урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка чыгымнар).

2) Торак пункт территориясен төзекләндерү (үлән һәм чүп үләннәрен чаптыру, юлларны кардан чистарту, тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, трактор өчен запас частьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алу, тракторчыга хезмәт килешүе буенча түләү һәм территорияне төзекләндерү буенча башка чыгымнар).

3) Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (янгыннарны сүндерү өчен җайлаштырылган техниканы тоту өчен бина төзү материаллары сатып алу һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка чыгымнар).

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек башлыгы П.М.КОРОЛЕВ